# ЛОКМАН ХӘКИМ

Бик күптән, иске заманда бар иде, ди, яши иде, ди, бер халык. Бай иде, ди, тук иде, ди, ул халык. Киң иде, ди йире, зур иде, ди, иле, иге-чиге юк иде, ди, суының, тавының. Бер елгасыннан сөт ага иде, ди, бер елгасыннан бал ага иде, ди, бер елгасыннан маи ага иде, ди. Бер тавыннан алтын – көмеш чыга иде, ди, бер тавыннан гәүһәр – якут тәгәри иде, ди, бер тавыннан - тимер дә булат. Кырларында богдаи үсә иде, ди, дөге пешә иде, ди, даласында үлән шаулый, чәчәк көлә иде, ди, тургай туй итә, карлыгач кыз алып, кыз бирә иде, ди. Күлендәге балык алтыннан иде, ди, көмештән иде, ди. Камышлыгындагы киек казы, киек үрдәге, торнасы санын фәрештә дә оныткан иде ди, шайтан санарга базмаган иде, ди...

Тормыш итә иде, ди, бу халык, бәхетле иде, ди, бу халык. Сандугачның сайравы белән ул йокысыннан уяна иде, ди, кәккүк кычкыруы белән ул йокыга ята иде, ди. Күбәләкнең уйнавы, бал кортының бызлавы астында ашыйсын ашый, эчәсен эчә иде, ди. Кояш бу ил өчен кояш кына түгел, ә күктәге якты нурлы дус иде, ди. Ул башын күтәреп чыккач илгә сәлам биш иде дә яшь егетне зифа кыз кочканча, карт абыстай сөйгән угылын үпкәнчә, бу иирне үбә иде, ди, коча иде, ди. Ул кырны көйдерми, бакчаны яндырмый иде, ди. Ул алманы пешерә йөземне, өрекне, шәфталуны өлгертә ди кавын - карбызны әлбә итә иде, ди, хәлвә итә иде ди. Бәхетле иде бу халык, көзен кыз бирә иде, ди, угыл өйләндерә иде, ди, туй итә иде, ди, язын кыз бактыра, ат чаптыра иде, ди, туй итә иде, ди, бу хадык. Ашаганы май иде, ди, эчкәне бал иде, ди, торган тормышы оҗмах иде, ди. Бала-чагасы ата-анага буйсына, хатын иргә сүз кайтармый иде, ди, ир хатынга кул күтәрми иде, ди... Кечек-олы, абый-эне йирле йирендә иде ди. Бае, бикәсе, хәлфәсе, остазы, түрәсе үз урынында иде, ди. Ханы хан иде, вәзире вәзир иде, ди, хикмәт иясе хәким иде, ди...

Менә шул халыкның бер падишаһсы бар иде, гадел идел, тугры иде, ди. Батыр иде, уңган иде, ди, ул падишаһ. Үзенең илендә падишаһлык сөрә иде, рәхәт-рәхәт еөн күрә иде, ди. падишап. Аның бар иде, ди, бер вәзире, гакыллы иде, ди, фикерле иде, ди, төпле иде, ди. Кырык еллык үткән эшен хәтерли иде, ди, кырык елга кырык киләчәкне күрә иде, ди. Ул падишаһлыкның бөтен эшен башкара иде, ди, булдыра иде, ди... Бар иде, ди, тагын бер хикмәт иясе, ул иде, ди, чын хәким, шул иде, ди, Локман хәким. Тынмый иде, саный иде, үлчи иде, ул. Халыкның бәхете өчен уйлый иде, ди, илнең бәрәкәте өчен сагышлый иде, ди, падишаһлыкның тынычлыгы өчен төшенә, пошына иде, ди. Ул көн — уйлы иде, ди, төн — сагышлы иде, ди. Аның алдында алтынның, көмешнең кадере юк иде, ди, энҗе - мәрҗәннең кыйммәте юк иде, ди. Дәрәҗәнең, данның базары юк иде, ди. Аның белгәне — Ходаның биргән хикмәте иде, ди, сөйгән иленең бәхете, рәхәте иде, ди. Падишаһлыкның бөтен хикмәте аның ихтыярында иде, ди. Ил дә, көн дә аңарга сүз кайтармый, вәзир дә хикмәтенә каршы килми, падишаһ та ул әйткән сүзгә тискәре эш күрми иде, ди. Ул хәким иде, ди, Локман хәким кебек хәким иде, ди. Һич яндышка әйтми, юлдан язмый, хәрәм йими, хәләлдән читләшми иде, ди...

Көннәрдән беркөнне хәким үзенең хикмәте белә бер яңы нәрсә белде, ди. Ходай Тәгалә аңа яңы бер сер әшкярә итте, ди. Бу хикмәт микән, шайтан саташтыруы микән дип башта ул икеләнде, ди, уйланды, ди, тәһарәтле хәлдә үзенең хикмәте белән тагы тикшерде ди: тагы шул хикмәт килеп чыкты, ди. Хәкимнең бу ачышы яңы иде, ди, зур иде, ди, искиткеч куркынычлы иде, ди. Ул вәзирне чакырды, ди, падишаһны күрде, ди, ачарга серле хикмәтне сөйләде, ди:

— Падишаһым-солтаным, Ходай Тәгалә безнең илемезгә бер ягъмур яудырачак. Шул ягъмурның суы дәрьяларга, елгаларга, инешләргә, чишмәләргә төшәчәк. Шул ягъмур суы катышкан суны эчкән кеше гакылдан язачак, исәпне-хисапны югалтачак, юлдан язачак, тугрыны кәкредән, акны карадан, хәләлне хәрәмнән, дустны дошманнан аера алмаячак. Падишаһым-солтаным, син илнең падишаһсы булганга вәзир хәзрәте илнең башкаручысы булганга, мин Ходайның кечкенә бәндәсе, үземнең хикмәтем белә маташканга безгә хәзердән су хәзерләргә кирәк - падишаһ, вәзир, хәким гакылыннан язмасын вә гакылдан язган башбаштак халыкны жиңеллек белән идарә итә белсен өчен кирәк...

Хәкимнең сүзенә падишаһ каршы килмәде, ди, вәзип дә сүз кайтармады, ди, өчесенә дә жятәрлек су хәзерләтте, ди...

Менә беркөнне кояш баеды ди айны болыт пәрдәләде, ди, җил-давыл күтәрелде, болыт кабарды, күк күкрәде, яшен яшьнәде, ди, шуннан ягъмур ява башлады ди... Яуды, ди, ягъмур, көн яуды, ди, төн яуды, ди... Болынны су басты, даланы күл итте, ди. Инешне елга итте, елганы Иделгә орды, ди... Менә тагы кояш чыкты ди, көн ачылды, ди... Көн белә бергә бөтен шәһәрнең олуглары-кечекләре, өйнең атасы-анасы, баласы-чагасы урамга чыкты, багчага тулды, ди... Һәммәсе туйга барган кебек киенде, ди, ясанды, ди... шатланды, ди, рәхәтләнде, ди. Кинә-хәсрәт бетте, ди, дошманлык онытылды, ди, ярлы белән бай арасында, ямьсез белә матур арасында, куркак белә батыр арасында аерма калмады, ди, бар да шатланды, ди, бар да сөенде, ди, бар да җырлады, бар да көйләде, барысы да берсен - берсе сөйде, ди. Дошманның дустлашуына, ярлының баюына, зәгыйфьнең таза кебек кылануына вәзир аптырап калды, ди, падишаһ хәйран булып торды, ди, хәким бер сүз дә димәде, ди, ни күрсә шуны язды да язды ди... Көн үтте, ди, төн үтте, ди. Халык бәйрәм итүдән һаман туктамады, ди... Менә көтелмәгәндә халык арасында бер хәбәр чыкты, ди, ул авыздан авызга сөйләнде, ди, ул зурайганнан зурайды, ди.

— Вәзир гакылдан язган икән, вәзир шашкан икән, вәзир исәпне югалткан икән, — диелә башланды, ди.

Хәким моны да язды, ди.

Ләкин халык көннән-көн: «Гакылдан язган вәзир белә ничек падишаһлык башкарылсын?» — дип тавышлана башлады, ди.  Ахырдан сарай янына килеп:

— Төшсен гакылдан язган вәзир! – дип, бик каты гауга куптарды, ди. Хәким, вәзир, падишаһ утырдылар, ди... Хәким:

— Халык вәзирне узе кебек җүләр түгеллеген сизенде. Вәзир халык белән бер төстә, бертөрле булырга кирәк, шуңар күрә хәзрәтләре дз халык эчә торган судан эчсен, - дип әйтте, ди...

Падишаһ та мәгъкуль күрде, ди, вәзир дә баш иде, ди, шуннан халык эчә торган судан эчте, ди.

Шуннан соң ук вәзирнең күзе кызарды, төсе ялтырады, кайда — ерактамы, якындамы, әллә нинди күңелле нәрсә күргән кебек булды, ди. Башының авырлыгы, уеның тирәнлеге бердән очты, ди, аягының авырлыгы бетте, ди... Арттагы кырык еллык аның гөмбәсе онытылды, ди, алдагы кырык еллык киләчәк аның күз алдыннан югалды, ди. Ул да халык арасына чыкты, ул да халык кебек туй-бәйрәм итәргә тотынды, ул да халык кебек әллә нәрсәгә сөенде, ди. Ерактан чакырып торган кебек булган матур тормыш — оҗмах тормышына ул да сәлам бирде, ди. Менә халык арасында:  « Вәзир терелгән икән, вәзир гакылга кайткан икән», —  дигән хәбәр таралды, ди. Һәммә кеше халкына еллар буе хезмәт иткән вәзирнең сәламәтләнүе өчен бәйрәм итте ди. Кызлар егетләр белә кочышты, сөеште, ди, ирләр хатыннар белә үбеште, ди, уйнашты, ди... Падишаһ вәзирнең җүләрләнүенә, озын еллар падишаһлыкның башында булуын онытып, җүләр малайлар белә биюенә, кыйлынуына, әллә нинди мәгънәсез йырлар йырлавына, иң тиленең дә башына килмәгән хыяллар белә саташуына кайгырды, ди, хәсрәтләнде, ди. Тирә - күрше падишаһлыкларының вәзирләре арасында иң гакыллысы, иң төплесе дип саналган зур вәзирнең адәм мәсхәрәсе булып йөрүенә хурланды, ди...

Хәким моны да язды, ди...

Балалар үзләрен зур итеп, хезмәтчеләр үзләрен хужа итеп, ярлылар үзләрен бай итеп, байлар үзләрен миллионер итеп, наданнар үзләрен галим итеп, җүләрләр үзләрен хәким итеп, түрәләр үзләрен вәзир итеп җүләрләнгәнгә, вәзир дә үзен вәзирләрнең вәзирләре итеп җүләрләнә башлады, ди. Ул да үзенә - үзе падишаһлыкны башкаруда хәтергә килмәгән җүләрлекләр уйлый башлады, таба башлады, ди. Ул үзенең исәпсез-хисапсыз планнарын падишаһка боерык чыгарырга димли башлады, ди... Беркөнне ул шәһәрнең уртасыннан ага торган, тирә-юненә энже-мәрҗән чәчә торган зур суны шәһәр читеңдәге тау башына

мендерү кирәклеген сөйләде, ди... Халык кул чабып кабул итте, ди... Икенче көнне айдагы Зөһрә кызны падишаһка хәләл хатынлыкка сорарга җаучы йибәрергә булды, ди...

Өченче көнне сәмруг кошка атланып Каф тавы артына барып мәмләкәтләр алырга булды, ди... Халык боларны да сөенә-сөенә кабул итте, ди... Вәзирнең шул планарына падишаһ көлеп-елмаеп кына җавап бирә килә иде ди... Вәзирнең җүләрлегенә мөнасиб падишаһлык күрсәтә алмаганына вәзир падишаһның гакылына зарар килүне сизенде, ди... Халык арасында колактан колакка падишаһның жүләрләнү хәбәре йөри башлады, ди... Ул хәбәр олылардан кечкенәләргә күчеп, өйдән урамга чыгып, урамнан базарга җитеп, базардан авылларга китеп, тиз вакытта бөтен мәмләкәткә таралды, ди... Һәркемнең авызында бер сүз:

— Падишаһ гакылдан язган икән, падишаһ жүләрләнгән икән,— иде, ди...

Озак вакыт үтмәде ди, бөтен халык шул уй белән тулды, ди. Падишаһ җүләрләнгән, падишаһ гакылдан язган!.. Вәзир падишаһка никадәр садыйк булса да, ул үзе дә шул сүзне дөрестләде, ди, ул да шулай икәнен әйтте, ди... Жүләр падишаһ белән ничек падишаһлык көтәргә?! Падишаһны төшерергә кирәк дигән уй китте, ди, халыкта... Падишаһ, хәким киңәшләштеләр, ди, уйлаштылар, ди... Хәким:

— Сезгә падишаһым-солтаным, халык эчкән тилерткеч судан эчә башларга кирәк,— дип әйтте, ди. Падишаһ:

— Син дә шулай итәмсең?— дип сорады, ди, хәкимнән!

— Юк, падишаһым-солтаным, минем Ходай тарафыннан йөкләтелгән бурычым бар — халыклар жүләрләнгәндә нинди юлларда жүләрләнә, нинди эшләр эшли, нинди жүләрлек баскычлары үтә — шуны җентекләп бару вә шуларны киләчәк буынга белдерү. Мин кечкенә кеше, жүләр халык үзенең арасында вәзир юклыгын сизенде, падишаһсы үзе кебек түгеллеген аңлады. Ләкин хәким юклыгы аның күзенә ташланмас,— диде, ди. Шуннан падишаһ та тилертә торган суны эчте, ди. Аның җилкәсеннән бердән дәүләт эшләренең авырлыгы төшкән кебек булып китте, ди. Ул үзен-үзе утыз елга яшәйгән, утыз батманга җиңеләйгән хис итте, ди. Биләүсәдәге бала кебек, уйсыз көләргә, уйнарга, сөенергә тотынды, ди... Ул да халык арасына чыкты, ди, падишаһ булып чыкты, ди. Халык жүләр падишаһны сөя-сөя каршы алды, ди.

Хәким моны да язды, ди.

Падишаһның жүләрләнүе дә падишаһча булды, ди. Ул үзен-үзе падишаһларның падишаһсы, хәкимнәрнең хәкиме итеп уйлый башлады, ди. Ул беренче ярлыгында элгәреге бөтен сүзләрнең мәгънәсен тискәре аңларга боерды, моңарча чыккан бөтен фәтвалар, кануннарны тискәречә гамәл итәргә кушты, ди... Халыкка падишаһның бу боерыгы бик хикмәтле кебек тоелды, ди. Ул бердә бөтен сүзләрнең мәгънәсен үзгәртте, ди, гакыллы урынга - тиле, җүләр, галим урынына – надан, канун дигән урынга - канунсызлык, тынычлык урынына - башбаштаклык, хәким урынына — шыртиле...Шуның артыннан башка нәрсәләр дә үзеннән-үзе үзгәрде, ди. Шул ярлык буенча, бай ярлы булырга, ярлы бай булырга, кечкенә зур булырга, олуг кечек булырга, надан галим булырга тиеш булды, ди. Өйдә бала баш булды, ди, ата буен сынды, ди, кыз ана булды, ана бала булды, ди... Җүләр хәким булды, хәким җүләр булды, ди...

Хәким боларны да язды, ди...

Җүләр падишаһ, шашкан вәзир, тилергән сарай эчендә хәким үзенең хикмәтенең кирәге юклыгын сизенде, ди. Ул бер төнне каләмен, камыш намазлыгын, суын күтәреп чыгып, падишаһ сараеннан качты, ди... Шәһәр янындагы тау тишегенә күченде, ди... Падишаһ та, вәзир дә хәкимнең юклыгын күрмәделәр, ди... Араларында падишаһның юклыгын сизенгән халык, вәзир юклыгын да тойган халык хәкимнең югалуын сизенмәде, ди... Аңарга илтифат итмәде, ди.

Җүләр падишаһсы, тиле вәзире, хәкимсез торуы берлә шашкан халык үзенчә, җүләрләрчә падишаһлык сөрергә тотынды, ди... Җүләр падишаһ, тиле вәзир, шашкан халыкның падишаһлыгы да, билгеле, жүләр юлдан китә иде, ди... Тик табигать кенә үзенең юлын үзгәртмәгән иде, ди... Элеккеге заманнан калган елгалар басуларны сулыйлар,

бабайлар эшләгән арыклар багчаларны сугаралар, әбиләр ясаган түтәлләр кавын-карбыз, кыяр-кишер үстерәләр иде, ди... Адәм баласының бөтен гакыллылыкларына, бөтен җүләрлекләренә өстән генә караган кояш та үзенең мәрхәмәтле җылысы белә йөземнәрне, өрекләрне, алмаларны, айваларны пешерә иде, үстерә иде, ди...

Падишаһлык җүләр булса да, һәр җүләр үзенчә җүләр иде, ди: падишаһ үз йирендә, вәзир үз йирендә, халык үз йиреңдә, халык үзенең җүләрлеген ил фикере итеп иргә белгертә иде, ди... Вәзир падишаһка тәкъдим итә, падишпһ әмер – фәрман, боерык яза, ярлык бирә иде, диХалыкның гомере эш белә үткәнгә, ул багчада, кырда, һөнәрханәдә эшләп йончып беткәнгә, халык «Эш бетсен» дигән фикергә килде, ди... Бу да вәзир аша падишаһка тәкъдим ителде, «Эш бетсен!» дигән ярлык чыгарылды ди... Эш беткәнгә һәммә халык ирекле, иркенле булып калды, ди, тагы бәйрәм итте, ди...

Хәким моны да язды, ди...

Хатыкның тормьншнда хәкиме, имамы, мөәззине, түрәсе, табибе, хәлфәсе һаман комачаулык иткәнгә, ул теләмәгәндә йокыдан уятып намазга чакырганга, нәрсәдән хәрәм дип тыйганга, ул сөйгән нәрсәләрне мөкруһ дип, кушмаганга, ул эшләргә теләгән нәрсәне зарарлы дип, кушмаганга - мәнгы иткәнгә алардан да котыласы килде, ди... Тагы вәзир аша падишаһка белгертте, ди. Падишаһ, тагы ярлык чыгарып хәким, имам, мулла, мөәззин, түрә, хәлфә, табиб булып халыкны комачаулауны тыйды, ди... «Халыкның иркенә, иркенлелегенә каршы килүчеләр каты җәза берлә хөкем ителәчәкләр»,— дигән фәрман таратты, ди, халык моннан да сөенде, ди. Шулай итеп, берсе артыннан берсе урман, кыр сакчылары, урам каравылчылары бетерелде, ди... Елга, арык, күпер осталары юк ителде, ди... Төрле низагларны, тартышуларны карауччы казыйлар, канун-шәригатьне җентекләп торучы мөфтиләр югалтылды. ди...

Ләкин халык һаман да үзе теләгәнчә рәхәтләнеп, оҗмахтагы кебек булып китә алмады, ди: иске гадәте буенча кереп калган йолалары бетмәде, ди. Ул һаман әле үзен-үзе тәмам ирекле, иркенле кебек күрә алмады, ди. Берсе килеп: «Мин синең күршең» дип, күршелек хакы сорады. Берсе: «Мин синең анаң» дип, аналык хакы теләде, берсе: «Мин синең хатының» дип, хатынлык хакы эстәде, берсе: «Мин синең балаң» дип, балалык хакы үтенде, ди... Халыкны бу комачаулыктан коткарыр дигән сүзләр бетерелде, хак, хокук дигән сүзләр истигъмальдән чыгарылды, шул боерыкка каршы килгәннәрне җәзалар өченкаты әмерләр бирелде, ди. Иске йоласы буенча халык һаман алыш – биреш итеп маташканга, кавынны карбызга, алманы өреккә, богдайны басмага, алтынны – көмешкә, паласны кәвешкә алыштырып килә иде, ди...Монда да алманың санын санап, алтынның мыскалын үлчәп, басманың аршин тигезләп йөдәп бетә иде, ди, уңайсызлана иде, ди.

Падишаһлыкның йстендәге бу авырлыкны да бетерер өчен: «Бөтен эгъмале әрбәганың хөкеме калмады, исан – хисап бетерелде!» – дип ярлык чыгарды, ди. Моннан соң падишаһ үзенең падишаһларның падишаһы сыйфатына мөнасиб, вәзирнең вәзирләрнең вәзирләре мәкаменә муафик эшләр эшләргә тотынды, ди: ул Каф тавы артына качкан, төн буе кояшны яшереп тора торган пәриенә сугыш игълан итте, ди....Үзенең дошман күрше падишаһсын авыр хәлгә төшерер өчен бөтен дөньядагы ишәкләрне су ташудан, утын китерүдән азат итеп ярлык чыгарды, ди. Дошман мәмләкәтләргә айның нуры төшмәсен өчен айның сул ягына койма коярга кушты, ди... Диңгезнең суын татлыландырыр өчен аны, түгеп, алмаштырырга фәрман итте, ди... Сахраның ком тузанын бетерер өчен Дәҗлә белә Форатка, Амудәрья белә Сырдәрья, Агыйдел белә Кара иделгә уңнан сулга, көннән төнгә, кояш баешыннан кояш чыгышына агарга кушты, ди.

Гарәбстандагы хаҗиларга авырлык булмасын өчен, алар эсселектән сусамасын өчен Байкал күленнән боз китерергә ярлык чыгарды, ди... Падишаһ көн дә яңыдан -яңы шаккатыргыч әмерләр, фәрманнар чыгарды, ди.

Хәким шул җүләрлекләрне һәммәсен яза килде, ди.

Кояш һәркөнне чыкты, һәркөнне батты, ди. Падишаһның әмерен тотмаенча елгалар иске урынында акты, диңгез суы һаман тозлы көенчә калды, ди. Көн үтте, ди, ай үтте, ди, халыкның бер төрлесе бу исереклектән айный башлады, ди, кайберләре исергәннән исерә

барды, ди… Моңарчага кадәр бер фикер, бер уйда, бер исереклектә булган халык бүленә башлады, ди, аның арасына төрлелек керде, ди… Берсе-берсен:

— Бу җүләр түгел! Бу тиле түгел! - дип гаепләү башланды, ди… Берсе өстеннән берсе тору күбәйде, ди…Шуның өчен ярлык чыкты…

— Җүләр түгеллектә гаепләнгәннәрне хөкем итәр өчен яңы мәхкәмәләр төзелде. Халыкның файдасын, тынычлыгын саклар өчен, җүләр өчен шымчылар куелды, ди… Гаеплеләрне җәзалар өчен палачлар чакырылды, ди. Шулай итеп торганда халык үзеннән-үзе дурткә бүленде, ди: тиле-миле, җүләр, шыртиле, гакыллы…Падишаһның әмере белә идарә эше шыртилеләр кулына бирелде… Гакыллылар дәүләт дошманнары дип ителеп, башларын чабу гадел табылды… Тиләләр, икенче дәрәҗәдә ителеп, идарә эшенә катыштырылмады, тиле - миле сансыз, кадерсез бер гөруһ булып калды, ди… Шуңа күрә гакыллылар үзләрен җүләр иттереп күрсәтер өчен, тиле-милеләр тиле иттереп танытыр өчен, җүләрләр шыртиле дәрәҗәсенә менәр өчен төрле хәйләләргә кереште, ди… Халык тиле бәрән орлыгы ашады, ди, түрәләр, мирзалар гашиш, әфъюн капты, ди, сәүдәгәрләр аршынчылар шәраб, аракы эчте, ди…

Ләкин арага кергән төрлелек, берсенә берсе ышанмау һаман тирәнәйде, ди… Шуны бетерер өчен падишаһ җитмеш җиде мең гакыллының башын бердән кисәргә кушты, ди… Аның белән дә бетмәде, ди… җитмеш җиде мең тиле-милене яндырырга фәрман итте, ди… Аның белән дә халык тигезләнмәде, ди… Күрше мәмләкәттән житмеш җиде мең җүләр китерергә дә боерды, ди…Ләкин аның белә дә тынычлык кайтмады, ди… һәр гөруһ берсен берсе гаепләде, ди, берсенә берсе ышанмады, ди. Падишаһлык эченә зур дошманлык керде, ди… бала атасына каршы, ата баласына каршы, күрше күршегә каршы шымчылык итте, ди. Ата угылын, ана кызын белмәде, ди… Һәрбер гөруһ бу тынычсызлыкта икенчесен гаепләде, ди… Идарә башындагы шыртилеләр җүләрләрне, тиле-милеләрне падишаһлыкка дошман итеп игълан итте, ди, аларны тагы кисте,ди,  чапты, ди. Адәм каны елга булып акты, ди…

Халык һаман тынмады, ди… Менә идарә башына жүләрләр менде, ди… Алар шыртилеләрнең тамырын корытырга керəште, ди… Үзен, баласын-чагасын, нәселен-нәсәбен кисте, ди, суйды, ди… Илен, йортын яндырды, ди, көйдерде ди. Тормыш һаман тынычланмады, ди… Идарә тиле-милеләр кулына күчте, ди, алар да уңнан да, сулдан да үзләренең дошманнарыннан туйганча үч алдылар, ди. Дөньялар кадәр кан агыздылар, ди, дәрьялар кадәр яшь түктерделәр, ди. Ләкин тынычлык һаман килмәде, ди…

Менә тилереп йөрер өчен халык тиле бәрән орлыгы таба алмый башлады, ди. Олуглар, мирзалар, түрәләр гашиш, әфьюн таба алмый башладылар, ди. Сатучылар, һөнәрчеләр шәраб-аракы таба алмый башладылар, ди - бары да бетте, ди, бары да югалды, ди. Халык тагы берсен берсе кырышты, ди, кисеште, ди. Падишаһ та аптырады, ди. Вәзир йөдәп калды, ди.

Хәким һаман язды да язды, ди…

Менә беркөнне күк күкрәде, яшен яшьнәде, ягъмур ява башлады, ди. Көн яуды, ди, төн яуды, ди, жиде көн яуды, ди, җиде төн яуды, ди. Инешләр елга булды, ди, елгалар дәрья булды, ди, сахралар баткаклыкка әверелде, ди. Шыртиле дә, җүләр дә, тиле-миле дә, гакыллы да, падишаһ та, вәзир дә өеннән чыга алмады, ди, берсен берсе суя алмады, ди… Менә җиде көн, җиде төн үтте, ди… Халык барысы да - баласы-чагасы, олугсы-кечесе йокыга китте, ди. Көн йоклады, ди, төн йоклады, ди. Җиде көн йоклады, ди, җиде төн йоклады, ди… Төн уртасында әтәч тә кычкырмады, ди. Таң алдында сандугач та сайрамады, ди…

Менә бердән бөтен халык уянды, ди, мәрттән уянган кебек уянды, ди… Бар да урамга чыкты, ди… Ни күзе белә күрсен: шәһәр янган, таланган, юл бозылган, күпер ватылган, арык җимерелгән, багча такыр басу - кырга әверелгән, кыр-басу дала булган… Халык сәләмәләнгән, бөлгән, беткән, бетләгән. Мәсҗеднең манарасы ауган, мәдрәсәнең гөмбәзе җимерелгән, хамамның фонтаны туктаган. Нә кибет, нә магазин, нә кәрвансарай, нә йорт, нә сарай калган. Мал-туар, кош-корт - бар да юк булган. Ил корыган, кипкән, Яәҗүҗ-

Мәэжүҗ үткән кебек сары балчыкка кадәр корыган… Урамнарда күмелмәгән меңләп-меңләп башлар тәгәри. Шәһәр читләрендә өем-өем күмелмәгән адәм үләксәләре ята… Диварларда падишаһның җүләр боерыклары, ярлыклары, вәзирнең тиле әмерләре ыржаеп, көлгән кебек ярылып ята…

Падишаһ аптыраган, вәзир йөдәгән, халык йончыган. Һәммәсе әллә нәрсә эзли, һәммәсе әллә нинди бик зур газизен югалткан кебек карана, эзләнә… Һәммәсенең башында әллә нинди бер югалган нәрсә бар, ләкин һичберсе шуның нә исемен белә, нә урынын белә… Көн буе халык урамда, басуда, багчада эзли, эзләнә… Көн буе үзе теләгәнне таба алмый, нәрсә эзләгәнен хәтерли алмый… Төн буе ул гыйбадәт итә, зиярәтләргә барып Коръән укый. Еглый, ялвара… эзли, югалткан нәрсәсен таба алмый, хәтеренә китерә алмый… Ул өч көн, өч төн гиръян булып йөри…Өч көн, өч төн еглый, ялвара, күз яшь урынына кан түгә. Өч көн, өч төн үзенең кылган гөнаһлары өчен тәүбә кыла.

Менә тагын көн туа, менә тагын халык эзләргә чыга… Тагы алда падишаһ, аның янында вәзир, аның янында голямалар, мөфтиләр, аның янында түрәләр, аның янында сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, хәлфәләр, остазлар… Ирләр, хатыннар, балалар-чагалар…
Менә берсе:

– Хәким кая? - дип кычкыра… Бердән бөтен халык падишаһ, вәзир янында хәким юклыгын күрәләр.

– Хәким кая? Хәким кая?- дип кычкыралар. Һәммәсенең күз алдына киселеп ташланган өем-өем башлар, үтерелеп ташланган гәүдәләр күренә… Һәммәсенең күңеле «жу» итеп китә… Бердән һәммәсендә: «Хәким үтерелгән, хәкимнең башы киселгән!» - дигән уй тарала.

– Хәким үтерелгән… Без ничек хәкимсез торыйк? Хәкимсез ничек яшик?!

Бөтен халык тагы еглый, тагы ялвара… Тагы эзләргә тотына. Шәһәрдә юк, басуда юк, урманда да юк… Халык урамда тәгәрәп йөргән башларны актарына, анда да юк. Өелеп куелган гәүдәләрне актара, анда да юк… Хәким юк… Менә бердән хәким рухына җеназа укырга дигән фикер туа… Халык бөтен киселгән башларны җыйный, башы өзелеп ташланган гәүдәләрне туплый, җеназа намазына тотына… Ул көн буе шуларны күмә, үзе еглый, үзе ялвара, үзе тәүбә кыла, үзе күмә… Хәкимне күмәм дип күмә…

Менә әллә кемнең күзе тау тишегенә төшә… Ул аның эчендә картайган, агарган бер карт күрә, һаман яшь күзләреннән аның хәким икәнлеген таный:

– Хәкимне таптым, хәкимне таптым! - дип кычкыра…

Падишаһ, вәзир, голямалар, түрәләр, олуглар, кечекләр тау тишегенә килә… Барысы да тезләнәләр, баш ияләр, сәлам бирәләр:

– Әссәламе галәйкем, йә хәким!

Тау тишеге җавап бирми. Тагы бер мәртәбә баш ияләр, тагы бер мәртәбә сәлам бирәләр:

– Әссәламе галәйкем, йә хәким!

Хәким һаман җавап бирми… Падишаһ, вәзир, голямалар, түрәләр, бөтен халык сәждәгә баралар… Тагы:

– Әссәламе галәйкем, йә хәким!

Тау тишегеннән акрын гына:

– Вәгаләйкем әссәлам, - дигән бер тавыш ишетелә. Падишаһ башын ташка ора. Вәзир башына туфрак сиба, халык йөзенә тузан сөртә. Падишаһ ялвара, вәзир ялына, халык зар еглый… Хәкимне чакыра…

– Хәким, гафу ит безне, синең хикмәтеңне оныттык, шуның өчен бу бәлагә төштек. Гафу ит безне вә падишаһлыкны алып барырга хикмәтеңне күрсәт!…

Акрын гына хәким урыныннан калка… Саче, сакалы агарган… Тормышның авырлыгы аның билен бөккән…күзенең нурын югалткан… Өсте сәләмәләнгән, намазлыгы тишелгән… Өсте-башы каралган, керләнгән… бетләнгән… Ул ташларга тотына-тотына чыга… Бер кулына каләмен, бер кулына язган зур китабын хикмәтен күтәреп чыга…

– Мин, Алланың бәндәсе, сез тилереп саташып йөргәндә гакылымнан язмадым, менә шул вакытта күргән-белгәннәремне, тәҗрибәләремне яздым. Бер ел кара белә яздым. Карам бетте. Бер ел күз яшем белә яздым. Халкымның хәленә еглый-еглый күз яшем кипте. Бер ел каным берлә яздым… Инде каным да бетте…Минем әле язачак сүзләрем бетмәде. Менә шул хикмәтләр белә гамәл кылсаңыз, Алла сезне бәладән, казадан саклар, - диде… Халык үлем даруы тапкан кеби сөенде, ди, шатланды, ди, хәкимне кулында күтәреп, хәкимнең хикмәтен баш өстенә куеп шәһәргә китерде. ди. Ашарына, эчәренә булмаса да, киярлек киеме-салымы булмаса да, тормышның хикмәтен таптым дип, ул тыныч-тыныч йокыга ятты, ди

* * *

Менә ят бер тавыш, сугыш тавышы төн уртасында халыкны йокысыннан уятты, ди. Кальганең сакчылары бетерелгән булганга, каршы торырга халык арыган, йончыган булганга, көтелмәгән дошман шәһәргә җиңеллек берлә кергән, бөтен халыкны кисәргә, суярга тотынган иде, ди. Сарайларын, диваннарын җимерергә, яндырырга керешкән иде, ди. Килгән әһле салибчеләрнең гадәт-йоласы, дине, теле бөтенләй башка булганга, алар бу халыкның олугсын, кечесен, кадерлесен, газизен - һәммәсен дин дошманы дип кенә таныганга, алар кулыннан сарай да, мәхкәмә дә, мәсҗед тә, җамигъ та, мәктәп тә, мәдрәсә дә, көтепханә дә, һөнәрханә дә котыла алмаган иде, ди. Коръән дә, китап та, хикмәт тә - бер өлеше кара берлә, бер өлеше күз яше берлә, бер өлеше кан берлә язылган хикмәт китабы да утта яндырылган иде, көл ителгән иде, ди. Падишаһ та, вәзир дә, хәким дә, түрә дә, олуг та, кечек тә башы киселеп урамга ыргытылган. Суга батырылган иде, ди. Аның шәһәре, авылы, багчасы, бостаны, кыры, басуы утка бирелгән, бөтен йире, суы корытылган, бөтен мәдәнияте йир берлә якъсан ителгән иде, ди.

Бик озак елларга кадәр бу халыкның исеме дә онытылган, аның гадел падишаһсы да, гакыллы вәзире дә хәтердән чыккан, аның хәкиме дә, Локман хәкимгә тиң хәкиме дә исеме вә хикмәте берлә бергүк югалган иде, ди.

Менә бик күп еллар үтеп, бик күп сулар агып, килгән салибче дошманнар куылып, шәһәрләр, йирләр, ирләр кайтарылгач кына, шәһәрнең ватыклары астыннан, чүп-чар арасыннан кан берлә язылган көйгән бер кәгазь, хәкимнең хикмәтенең бер бите табылган иде, ди. Вә бик озак мәшәкатьтән соң түбәндәге сүзләр укылган иде, ди: «1. Тәңренең кояш йылысы һәркемгә җитәрлек. Башкаларның иркенә, иркенлегенә тукынма, Тәңренең биргәнен кызганма, илең хөр булса, йортың тыныч булыр. 2. Изге адәм фәрештә түгел, усал адәм шайтан түгел, кем булса да ул синең кардәшең - Адәм угылы адәм, аны хөрмәт ит. 3. Ир тормышы намус өстенә корыла, дәүләт тормышы тугрылык өстенә бина ителә. Падишаһ гадел булса, халык рәхәт яшәр. 4. Хикмәт бердер, аны риякярлар күп итте. Мәмләкәттә канун никадәр аз булса, канунны бозучы да шулкадәр аз булыр».

Моңарга башка да кәгазьдә аерым сузләр булса да, алары танылмады, ди, вә, шулай итеп, ул хәкимнең, чын хәкимнең, Локман хәкимгә тиң хәкимнең башка язганнары адәм баласыннан гаиб булды, ди. Аның хикмәте бу көнгә кадәр табылмый калды, ди.

**Аңлатмалар һәм искәртмәләр:**

Шәфталу – персик

Төшенү – уйлану

Хәрәм йитми – хәрәм ашамый

Әшкярә итү – ачу, белдерү

Мөнасиб – тиешле, яраклы

садыйк – турылыклы, дус

Буен сну – буйсыну

Мәнгы итү – тыю

Истигъмал – кулланыш

Эгъмале әрбәга – дүрт гамәл

Мәкам – дәрәрҗә, урын

Муафикъ – яраклы

Дәҗлә – Тигр елгасы

Форат – Евфрат елгасы

Гөруһ – төркем

Хамам – мунча

Гирьян булып йөри – елап йори

кальга - крепость

Диван – бу урында: китап

Бостан – бакча

**Локман Хәким.** Әкият 1923 елда гарәп имлясында язылган. Кульязма килеш сакланган. 23 бит. Әсәр 1990 елда русчага тәрҗемәдән кабататарчага тәрҗемә ителеп, «Идел» журналының 6 нчы санында басылды. Тәрҗемәче Солтан Шәмси кулыннан әкият бик матур килеп чыккан. Биредә Г. Исхакый үзе язган татарча текст бирелә. Локман Хәким - Көнчыгыш халыкларында акыл иясе, хикмәтле зат.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 5 том. - Казан:

Татарстан китап нәшрияты, 2009. Б. 149-158

Текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче

**Гайнанова** Лена Рәшит кызы